**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**Исполнительный комитет Азнакаевского муниципального района**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Азнакай муниципаль районы башкарма комитеты**

ул. Ленина, д..22, г. Азнакаево, 423330
Тел./факс (885592) 7-24-71, 7-26-97
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

Ленин урамы, 22 йорт, Азнакай шәһәре, 423330
Тел./ факс (885592) 7-24-71, 7-26-97
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

# ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

**« 26 » 04 2023 ел** **№ 99**

Азнакай муниципаль районы башкарма комитетының 2019 елның 22 мартындагы 67 номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы мәдәният һәм мәгариф өлкәсендә оешмалар тарафыннан хезмәт күрсәтү шартларының сыйфатын бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет турындагы нигезләмәне раслау хакында» карары белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының мәдәният һәм мәгариф өлкәсендә оешмалар тарафыннан хезмәт күрсәтү шартларының сыйфатын бәйсез бәяләүне уздыру буенча иҗтимагый совет турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында (01.08.2019 № 245 карар редакциясендә)

«Россия Федерациясе субъектларында гавами хакимиятне оештыруның гомуми принциплары турында» 2021 елның 21 декабрендәге 414-ФЗ номерлы Федераль законны үтәү йөзеннән Азнакай муниципаль районы башкарма комитеты карар бирә:

1. Азнакай муниципаль районы башкарма комитетының 2019 елның 22 мартындагы 67 номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы мәдәният һәм мәгариф өлкәсендә оешмалар тарафыннан хезмәт күрсәтү шартларының сыйфатын бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет турындагы нигезләмәне раслау хакында» карары белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының мәдәният һәм мәгариф өлкәсендә оешмалар тарафыннан хезмәт күрсәтү шартларының сыйфатын бәйсез бәяләүне уздыру буенча иҗтимагый совет турында нигезләмәгә (01.08.2019 № 245 карар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешне кертергә:

1.1.2 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

«1.2. Үз эшчәнлегендә сыйфатны бәйсез бәяләү буенча Иҗтимагый совет Россия Федерациясе Конституциясе, федераль конституциячел законнар, федераль законнар, Россия Федерациясе Президенты указлары һәм күрсәтмәләре, Россия Федерациясе Хөкүмәте карарлары һәм күрсәтмәләре, Татарстан Республикасы Конституциясе, Татарстан Республикасы законнары, Татарстан Республикасы башлыгы (Рәисе) указлары һәм күрсәтмәләре, Татарстан Республикасы Хөкүмәте карарлары һәм күрсәтмәләре, муниципаль хокукый актлар, шулай ук әлеге нигезләмә белән җитәкчелек итә.».

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда веб-адрес буенча: http://pravo. tatarstan.ru бастырып чыгарырга һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет-телекоммуникация челтәрендә веб-адрес буенча: http://aznakayevo.tatar.ru урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Җитәкче А.Х. Шәмсетдинов